ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 113-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.У. Әхмәтов, О.М. Воронова, Р.С. Гайнетдинова, С.М. Захарова, А.И. Зыятдинов, А.С. Созинов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 113-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре
2025 елның 25 сентябре
№ 411-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.У. Әхмәтов,
О.М. Воронова,
С.М. Захарова,
А.И. Зыятдинов,
А.С. Созинов,
Р.С. Гайнетдинова
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә:

а) 1 пунктның «в» пунктчасына «, шулай ук идентификацияләү мөмкин булмаган һәм мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелмәгән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән авырулар булганда һәм халәтләрдә ашыгыч һәм кичектергесез рәвештә медицина ярдәме күрсәтү буенча» сүзләрен өстәргә;

б) түбәндәге эчтәлекле $6^3$ пункт өстәргә:

«$6^3$) Татарстан Республикасы законнары нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә ишетү органнарын протезлау буенча хезмәтләр күрсәтү буенча;»;

2) 2 өлештә:

а) дүртенче абзацта «һәм мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек башкармый торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) тугызынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга;

в) унынчы абзацта «һәм ишетү органнарын протезлау» сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

Закон проекты белән Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәсе булган сәламәтлек саклау өлкәсендәге аерым чараларны финанслау тәртибен үзгәртү тәкъдим ителә, аларны финанс белән тәэмин итү гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләренең территориаль программасы кысаларында гамәлгә ашырыла.

Хәзерге вакытта идентификацияләү мөмкин булмаган һәм мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелмәгән гражданнарга мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелгән авырулар булганда һәм халәтләрдә ашыгыч һәм кичектергесез рәвештә медицина ярдәме күрсәтү Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды аша финанслана. 2026 елның 1 гыйнварыннан әлеге чараны Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы аша финанслау тәкъдим ителә.

Законнар нигезендә гражданнарның аерым категорияләренә ишетү органнарын протезлау буенча хезмәтләр күрсәтү дәүләт гарантияләре программасына кертелмәүгә бәйле рәвештә, әлеге хезмәтләр күрсәтү төрен аерым пунктчада бәян итәргә һәм 2026 елның 1 гыйнварыннан аны, Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондын читләтеп үтеп, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы аша финанслауны гамәлгә ашыру тәкъдим ителә.

25 статьяның 2 өлешендәге дүртенче абзацында «һәм мәҗбүри медицина иминияте өлкәсендә эшчәнлек башкармый торган» сүзләрен төшереп калдырырга тәкъдим ителә. Шулай итеп, агымдагы финанс елында һәм план чорында Татарстан Республикасы территориясендә гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасын гамәлгә ашыруда катнаша торган медицина оешмалары тарафыннан җенси юл белән тапшырыла торган, кеше иммунодефициты вирусы китереп чыгарган авыруларда, барлыкка килгән иммунодефицит синдромында, туберкулезда, психик тайпылышларда һәм тәртибендә тайпылышларда күрсәтелә торган беренчел медицина-санитария һәм махсуслаштырылган медицина ярдәме күрсәтү Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансфертлар исәбеннән Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды тарафыннан тулы күләмдә гамәлгә ашырылачак.

Закон проектын гамәлгә ашыру сәламәтлекне саклау өлкәсендә санап үтелгән чараларны финанслауны, гражданнарның сәламәтлеген саклауга һәм медицина ярдәменә хокукларын киметүгә китермәячәк, законнарда каралган гражданнарның категорияләренә ишетү органнарын протезлау буенча хезмәтләр күрсәтү сакланачак һәм тулы күләмдә башкарылачак.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү «Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлау һәм ишетү органнарын протезлау буенча хезмәтләр күрсәтү турында» 2015 елның 2 апрелендәге 214 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына тиешле үзгәрешләр кертүне таләп итәчәк.

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.